ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15 03 2022 г. № 131

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты планлаштырылган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлегенә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 682 номерлы карары белән расланган индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты планлаштырылган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлегенә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5.1 пунктының беренче абзацында «индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яки реконструкцияләү» сүзләрен «индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү («Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы

Федераль закон нигезендә, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш)» сүзләренә алмаштырырга

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында басма матбугатта урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә.Хаҗиевка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкченең беренче урынбасары Р.Г.Шакиров

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН МКУ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874